# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
# **КАРАРЫ**

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасында күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында

«Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга дәүләт ярдәм фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесе Г.Л. Удачинаның, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Э.С. Шәрәфиевнның, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары – Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы В.С. Филатовның, Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Н.В. Бутаеваның, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты рәисе Д.Ф. Нургалиевның, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы әгъзасы О.А. Ажимованың, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының махсус хәрби операциядә катнашучы якташларга ярдәм итүне оештыру буенча волонтерлар координаторы Л.И. Коткованың мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасында күрсәтелә торган ярдәм чаралары турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына:

2.1. Махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренә, махсус хәрби операциядә катнашкан һәлак (вафат) булганнарның гаиләләренә аерым игътибар биреп, социаль-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм күрсәтү буенча сайлау округлары территорияләрендә эшне активлаштырырга.

2.2. Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм Россия Федерациясенең яңа субъектлары халкы өчен гуманитар ярдәм җыю һәм аны җибәрү эшен дәвам итәргә.

2.3. Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын үткәрү һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү

кысаларында тематик чараларда, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, балалар һәм яшьләр белән очрашуларда актив катнашырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына:

3.1. Комитетлар карамагындагы мәсьәләләр буенча законнар мониторингын дәвам итәргә һәм, кирәк булганда, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр кертергә.

3.2. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга кирәкле ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен комитетлар карамагындагы мәсьәләләр өлешендә оператив карауны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары мәнфәгатьләрендә бурычларны комплекслы хәл итүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының җирле үзидарә органнары, «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга дәүләт ярдәм фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы, иҗтимагый оешмалар, башка кызыксынган органнар һәм оешмалар белән хезмәттәшлеген көчәйтү эшен, шул исәптән Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы территориясендә ярдәм итү мәсьәләләре буенча региональ ведомствоара комиссия эшчәнлеге кысаларында, дәвам итәргә.

4.2. Хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, заманча медицина реабилитацияләве технологияләрен кулланып, медик-социаль, психологик, психологик-психотерапевтик һәм башка ярдәм буенча, шулай ук пациентларны, аларның сәламәтлеге торышын исәпкә алып, хезмәт эшчәнлегенә әзерләү буенча комплекслы хезмәтләр күрсәтү максатларында реабилитацияләү һәм социальләштерү республика үзәген булдыру мәсьәләсен карарга.

4.3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына социаль түләүләрнең һәм ярдәм чараларының бердәм республика базасын (реестрын) булдыру мөмкинлеген карарга.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренең махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына медицина ярдәме, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме, күрсәтү, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән махсус хәрби операциядә

катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына чираттан тыш медицина тикшерүләре үткәрү һәм аларны реабилитацияләү эшчәнлеген координацияләүне дәвам итәргә.

5.2. Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә һәм Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә махсус хәрби операция ветераннарына тулы күләмдә диспансер күзәтүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең региональ берләшмәсе), Татарстан Республикасы Кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе белән берлектә Татарстан Республикасында эш бирүчеләргә махсус хәрби операциядә катнашучы хезмәткәрләр гаиләләренә, махсус хәрби операциядә катнашкан һәлак (вафат) булган хезмәткәрләрнең гаиләләренә аерым игътибар биреп, ярдәм, шул исәптән социаль-көнкүреш ярдәм, күрсәтүне дәвам итү зарурлыгы турында хәбәр итүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына демобилизацияләнгән махсус хәрби операциядә катнашучыларны, аларның сәламәтлеге торышын исәпкә алып, эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү, шулай ук аларның яңа һөнәрләргә өйрәнүгә һәм алга таба эшкә урнашуга мотивациясен арттыру, шул исәптән «Кадрлар» илкүләм проектының «Хезмәт белән тәэмин итүнең актив чаралары» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында, эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

8.1. Балаларга һәм яшьләргә рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү кысаларында гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарына, хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү буенча волонтерлык хәрәкәтендә катнашуга җәлеп итү эшен көчәйтергә.

8.2. 2025 елгы җәйге сәламәтләндерү кампаниясе кысаларында махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм махсус хәрби операция ветераннары балаларының санын җәйге ялда арттыру мөмкинлеген карарга.

9. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына инвалид булган махсус хәрби операция ветераннарын адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү буенча һәм аларны инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен яраклаштырылган спорт

төрләре буенча ярышларда катнашуга әзерләү буенча системалы эшне оештыруны тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына махсус хәрби операция ветераннарын һәм аларның гаилә әгъзаларын патриотик юнәлештәге чараларда катнашуга, шул исәптән иҗат коллективлары составында, җәлеп итү эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

11. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

11.1. Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм махсус хәрби операция ветераннары гаиләләренең, махсус хәрби операциядә катнашкан һәлак (вафат) булганнарның гаиләләренә аерым игътибар биреп, мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү эшен көчәйтергә.

11.2. Демобилизацияләнгән махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә социаль ярдәм чараларын (муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына ата-ана түләвеннән башка йөрү, муниципаль гомуми белем бирү һәм муниципаль һөнәри белем бирү оешмаларында түләүсез туклану, җәмәгать транспортында түләүсез йөрү һәм башкалар) күрсәтү мөмкинлеген карарга.

11.3. Инвалид булган махсус хәрби операция ветераннары яши торган индивидуаль торак йортларны, күпфатирлы йортлардагы торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне тикшерү һәм яраклаштыру буенча кирәкле эшне оештырырга һәм ишегалды территорияләреннән аларның файдалана алуын тәэмин итү чараларын күрергә.

11.4. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына түләүсез психологик-психотерапевтик ярдәм күрсәтү кабинетлары эшен, шулай ук психологларның өйгә килеп эшләвен оештыруда ярдәм итәргә.

11.5. Медицина ярдәменә һәм реабилитацияләүгә мохтаҗ булган махсус хәрби операция ветераннары турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән мәгълүмат алмашуны тәэмин итәргә.

11.6. Тиешле муниципаль берәмлек территориясендә «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга дәүләт ярдәм фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы вәкилләренең эшчәнлеген оештыру өчен шартлар булдыру, шул исәптән җайлаштырылган (яраклаштырылган) биналар бирү, мөмкинлеген карарга.

11.7. Махсус хәрби операциядә катнашкан һәлак (вафат) булган якташларның истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләсен карарга.

12. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентына:

12.1. Махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен гуманитар ярдәм җыю һәм аны җибәрү, аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү эшен дәвам итәргә.

12.2. Луганск Халык Республикасы Халык Советы каршындагы Яшьләр парламенты һәм шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре территорияләрендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы социаль учреждениеләр белән аларның халкына кирәкле ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен оператив хәл итү максатларында хезмәттәшлекне дәвам итәргә.

12.3. Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын үткәрү һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү кысаларында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә «Җиңү Варислары: Ватанны саклаучылар» республика иҗади эшләр конкурсын үткәрүне тәэмин итәргә.

13. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

13.1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасында үткәрелә торган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында һәрьяклап яктыртырга.

13.2. Массакүләм мәгълүмат чараларында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен аңлатырга.

14. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 12 марты
№ 48-VII ДСП